**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**«Каравон» рус халык бәйрәмен уздыру турында**

2023 елда «Каравон» рус халык бәйрәмен уздыру максатларында һәм «Татарстан Республикасының бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталары турында» 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, җирле үзидарә органнары һәм иҗтимагый берләшмәләр тәкъдимнәрен исәпкә алып, «Каравон» рус халык бәйрәмен 2023 елның 28 маенда Татарстан Республикасы Лаеш районының Никольское авылында уздырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Каравон» рус халык бәйрәмен әзерләүне һәм уздыруны оештыруны тәэмин итәргә.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына «Каравон» рус халык бәйрәмен әзерләүне һәм уздыруны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга.

4. Җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә һәм оешмаларга «Каравон» рус халык бәйрәмен әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы
Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 02 май
№ 270